**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЕШ АВЫЛ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**423741, Аеш авылы,**
**Ленин ур.,34б нче йорт.**
**Тел/факс 3-44-41**

**e–mail: aish-akt.galeeva@yandex.ru**

**АИШЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423741, село Аишево,**
**ул.Ленина, дом 34б.**
**Тел/факс 3-44-41**
**e–mail: aish-akt.galeeva@yandex.ru**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28 февраль 2025ел №7

"Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль берәмлегенең Аеш авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннары йөрү өчен билгеләнгән урыннарны билгеләү турында"

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 ел №489-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Аеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 10.02.2025 ел Аеш номерлы Актаныш районы прокуратурасы тәкъдимен карап, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Аеш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Аеш авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1.1. хуҗасының милкендәге яисә файдаланудагы җир кишәрлекләрендә;

1.2. авыл җирлеге территориясендә халык күпләп җыелмый торган бушлыкларда, торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннарда, хуҗалары күзәтүе астында борынчыкта һәм бәйләвечтә килеш:

- Аеш авылында 16:04:060201:233 кадастр номерлы җир кишәрлегендә;

Бу территорияләрдә «Йорт хайваннарын йөртү» дигән язулы табличкалар урнаштырырга.

2. Йорт хайваннарын йөртү гражданнарның, хайваннарның иминлеген тәэмин итү, физик затларның һәм юридик затларның мөлкәте саклану шарты белән башкарылырга тиеш.

2.1. Этне урамда йөртү, озынлыгы этнең үз-үзен тотышын контрольдә тотарга мөмкинлек бирә торган бәйләвеч (этне тотып тора торган башка җайланма) кулланып башкарылырга тиеш (Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган исемлектәге, әлеге карарның 5 пункты нигезләмәләре кулланыла торган потенциаль куркыныч этләрне урамда йөртүдән тыш).

3. Рөхсәт ителми:

3.1. йорт хайваннарын балалар һәм спорт мәйданчыкларында, парклар, скверлар территорияләрендә, массакүләм ял итү урыннарында, балалар, мәгариф һәм дәвалау учреждениеләрендә, мәдәният объектлары янындагы территорияләрдә, хайваннар белән бергә йөрү өчен махсус объектлардан тыш, кибетләрдә иректе йөртү.

3.2. 3.1 нче пунктның гамәли көче. йөртүче этләргә кагылмый.

3.3. этләрне урамда йөргәндә караучысыз калдырырга;

3.4. этләрне алкоголь, наркотик яки токсик исерек хәлдә булган затлар, шулай ук яшь яки сәламәтлек торышы аркасында этләрнең хәрәкәтен контрольдә тота алмаган һәм урамда йөргәндә аларның агрессив тотышын кисәтә алмаган затлар белән урамда йөртү.

4. Йорт хайваны урамда йөргәндә барлык очракларда хуҗа үзе белән экскрементлар җыю өчен предметлар йөртергә һәм, подъездлар, баскыч, лифтлар, балалар мәйданчыклары, җәяүлеләр юллары, подваллар һәм торак йортларда һәм торак зоналарда гомуми файдаланудагы башка урыннарны да кертеп, кичекмәстән үзенә караган йорт хайваннары артыннан экскрементлар җыярга тиеш.

5. Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган исемлектәге потенциаль куркыныч этләрне, потенциаль куркыныч эт милек хокукында яисә башка закон нигезендә потенциаль куркыныч эт хуҗасының киртәләнгән территориясендә булган очраклардан тыш, борынчыксыз һәм бәйләвечсез йөртү тыела. Әлеге этнең булуы турында әлеге территориягә кергәндә кисәтү язуы ясалырга тиеш.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.Р.Ахатов